**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге башлыгы**

**карары**

**17 ноябрь, 2023 ел** **№ 11**

**«Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге Вильмон поселогында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 29 ноябрендә 15 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма-Юмья авыл җирлегенең Вильмон поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Вильмон поселогы, Тынычлык урамы, 5 нче йорт адресындагы торак йорт янында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге Вильмон поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Вильмон авылында юлларны төзү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, сууткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, Вильмон поселогында янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавлары, стволлары, күчергечләре, колонкалары, мотопомпалары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), янгын пирсларын урнаштыру, ремонтлау;

- коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- Вильмон поселогының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү:

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Оштырма-Юмья авыл башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Җирлек башлыгы С.В. Тимофеев

ОГРН 1021607752737
ИНН 1623001692